**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Түбән Шашы торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

“22” ноябрь 2019 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 22 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта, 2019 елның 22 ноябрендә 19 сәгать 30 минутта узган этаплы җыеннар нәтиҗәләре белән «Сез 2020 елда Күңгәр авыл җирлеге Түбән Шашы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- авыл җирлеге территориясендәге урам юлларына карата юл эшчәнлеге: Түбән Шашы авылында вак таш сатып алу һәм җәю, транспорт хезмәтләре өчен түләү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыенының беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 320 (өч йөз егерме ) кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә катнашкан граҗданнар саны 172 (бер йөз җитмеш ике) кеше, бу 53,75 % тәшкил итә..

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Риза» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 172 (бер йөз җитмеш ике) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Тубән Шашы авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

“Сез 2020 елда Күңгәр авыл җирлеге Тубән Шашы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме: - авыл җирлеге территориясендәге урам юлларына карата юл эшчәнлеге: Түбән Шашы авылында вак таш сатып алу һәм җәю, транспорт хезмәтләре өчен түләү.” мәсьәләсен кабул ителгән дип санарга.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Түбән Шашы авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Түбән Шашы авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күңгәр авыл җирлеге башлыгы Гарипова Г.Х..